**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге**

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә 2022 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**

**КАРАР**

2021 елның 11 декабре № 2

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясы, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советының 2020 елның 28 апрелендәге 5 номерлы карары белән кабул ителгән «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставының 16 статьясы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлегендә гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә (09.10.2020 ел, № 7 Ютазы муниципаль районы шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе советы карары белән кабул ителгән), «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә 2022 елда «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының» Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә үзара салым (бер тапкыр түләү) акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең 11.12.2021 ел, № 1 гражданнар җыены карары нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2022 елда үзара салымны 400 сум күләмендә (бер тапкыр түләнә торган түләү) кертергә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән көндезге формада укыган студентлар өчен 200 сум күләмендә җыярга, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның һәм аңа тиңләштерелгән затларны, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарын, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрне, 1,2 төркем инвалидларны, 80 яшьтән өлкәнрәк затларны, АЭС ликвидаторларын

һәм аларга тиңләштерелгән гражданнар категорияләрен үзара салым акчасын (бер тапкыр түләү) түләүдән азат итәргә.

2. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә М.Җәлил, Шәкүров, Тукай, Альберт Шамкин, Октябрь урамнары, шагыйрь Сирин, Декабристлар урамы, Яр урамы, Жуков урамы, Куйбышев урамы, Ютазы тыкрыгы, Славян тыкрыгы, Островский урамы, Гоголь урамы, Гладилов урамы буенча юлларны һәм тротуарларны норматив хәлгә китерү (төзелеш, реконструкция, асфальтлау, ремонт, вак таш салу, бордюрлы ташны алыштыру һәм урнаштыру, төзелеш материалларын сатып алу).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасының Бердәм Дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан мизгеленнән үз көченә керә һәм 2021 елның 11 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының бюджет-финанс комиссиясенә йөкләргә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Ютазы муниципаль районы
Урыссу шәһәр тибындагы поселогы
Башлыгы А. Ә. Шәфигуллин